ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31 март 2017ел № 1733

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә законсыз урнаштырылган реклама корылмаларын һәм тышкы мәгълүмат чараларын ачыклау һәм демонтажлау тәртибен раслау турында

«Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ санлы Федераль законның 19 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсе, шәһәр Уставының 9 маддәсе, Шәһәр Советының 2013 елның 30 маендагы 25/8 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә реклама корылмаларын урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турында нигезнамә, Шәһәр Советының 2012 елның 20 сентябрендәге 21/8 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә законсыз урнаштырылган реклама корылмаларын һәм тышкы мәгълүмат чараларын ачыклау һәм демонтажлау тәртибен кушымтада каралганча расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2017 елның 31 мартындагы
1733 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә
законсыз урнаштырылган реклама корылмаларын һәм тышкы мәгълүмат чараларын
ачыклау һәм демонтажлау
тәртибе

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә законсыз урнаштырылган реклама корылмаларын һәм тышкы мәгълүмат чараларын ачыклау һәм демонтажлау тәртибе (алга таба – тәртип) законсыз урнаштырылган реклама корылмаларын һәм тышкы мәгълүмат чараларын ачыклау, реклама корылмаларын һәм тышкы мәгълүмат чараларын демонтажлау турында күрсәтмәләр бирү, реклама корылмаларын һәм тышкы мәгълүмат чараларын демонтажлау тәртибен билгели.

Әлеге тәртип «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ санлы Федераль законның 19 маддәсе, Шәһәр Советының 2013 елның 30 маендагы 25/8 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә реклама корылмаларын урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турында нигезнамә, Шәһәр Советының 2012 елның 20 сентябрендәге 21/8 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә эшләнде.

3. Әлеге тәртиптә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

1) Законсыз урнаштырылган реклама корылмасы – рөхсәтсез урнаштырылган һәм (яки) эксплуатацияләнә торган һәм гамәлдәге срогы чыкмаган реклама корылмасы (алга таба – реклама корылмасы);

2) Законсыз урнаштырылган тышкы мәгълүмат чарасы – тышкы мәгълүмат чарасы паспортыннан башка муниципаль милек объектында урнаштырылган тышкы мәгълүмат чарасы.

4. Законсыз урнаштырылган реклама корылмаларын, тышкы мәгълүмат чараларын ачыклау, аларны демонтажлау турында күрсәтмәләр бирү Башкарма комитетның вәкаләтле органы – Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе (алга таба – АШТ һ ТҮИ) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Законсыз урнаштырылган реклама корылмалары, тышкы мәгълүмат чаралары ачыкланган очракта АШТ һ ТҮИ тарафыннан законсыз урнаштырылган реклама корылмаларын (тышкы мәгълүмат чараларын) ачыклау турында акт төзелә.

6. Реклама корылмасы, тышкы мәгълүмат чарасы законсыз урнаштырылган реклама корылмасын (тышкы мәгълүмат чарасын) ачыклау турында акт төзелгән вакыттан соң 7 көн эчендә бирелгән АШТ һ ТҮИ күрсәтмәсе нигезендә демонтажланырга тиеш. Реклама корылмасының, тышкы мәгълүмат чарасының хуҗасы, реклама корылмасы, тышкы мәгълүмат чарасы тоташтырылган күчемсез милкәт милекчесе яки аның башка законлы хуҗасы ачыкланган очракта, АШТ һ ТҮИ расписка буенча һәм (яки) почта аша җибәрү юлы белән реклама корылмасын, тышкы мәгълүмат чарасын демонтажлау турында күрсәтмә бирүне гамәлгә ашыра.

Почта аша җибәрелгән хат кире адрес буенча кайтарылган очракта, АШТ һ ТҮИ реклама корылмасының, тышкы мәгълүмат чарасының фотосурәтен теркәп,

демонтажлау турындагы күрсәтмәне «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыра.

Реклама корылмасын, тышкы мәгълүмат чарасын демонтажлау турында күрсәтмә бирүнең югарыда күрсәтелгән ысулларының теләсә кайсы тиешле дип санала.

7. Реклама корылмасының, тышкы мәгълүмат чарасының хуҗасы реклама корылмасын, тышкы мәгълүмат чарасын демонтажлау турында күрсәтмә бирелгән көннән соң бер ай эчендә реклама корылмасын, тышкы мәгълүмат чарасын демонтажлауны гамәлгә ашырырга, шулай ук күрсәтелгән күрсәтмә бирелгән көннән соң оч көн эчендә реклама корылмасындагы, тышкы мәгълүмат чарасындагы мәгълүматны алырга тиеш.

8. Реклама корылмасының хуҗасы билгеләнгән срокта әлеге тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән реклама корылмасын демонтажлау буенча йөкләмәне үтәмәгән яки реклама корылмасының хуҗасы билгеле булмаган очракта, АШТ һ ТҮИ реклама корылмасы тоташтырылган күчемсез мөлкәт милекчесенә яки аның башка законлы хуҗасына реклама корылмасын демонтажлау турында күрсәтмә бирә (реклама корылмасы муниципаль мөлкәт объектына яки күп фатирлы йорттагы бүлмә хуҗаларының гомуми мөлкәтенә әлеге бүлмә хуҗаларының реклама корылмасын урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә ризалыгыннан башка тоташтырылган очрактан тыш). Реклама корылмасы тоташтырылган күчемсез мөлкәт милекчесе яки аның башка законлы хуҗасы тиешле күрсәтмә бирелгән көннән соң бер ай эчендә реклама корылмасын демонтажларга тиеш. Реклама корылмасын демонтажлау, саклау яки кирәк очракта юкка чыгару реклама корылмасы тоташтырылган күчемсез мөлкәт милекчесе яки аның башка законлы хуҗасы хисабына гамәлгә ашырыла. Әлеге күчемсез мөлкәт милекчесенең яки аның башка законлы хуҗасының таләбе буенча, реклама корылмасының хуҗасы реклама корылмасын демонтажлау, саклау яки кирәк очракта юкка чыгару белән бәйле рәвештә тотылган чыгымнарны мөлкәт милекчесенә яки аның башка законлы хуҗасына кайтарырга тиеш.

9. Реклама корылмасы тоташтырылган күчемсез мөлкәт милекчесе яки аның башка законлы хуҗасы билгеләнгән срокта әлеге тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән реклама корылмасын демонтажлау буенча йөкләмәне үтәмәгән яки әлеге күчемсез мөлкәт милекчесе яки аның башка законлы хуҗасы билгеле булмаган очракта, реклама корылмасын демонтажлау, саклау яки кирәк очракта юкка чыгару шәһәр бюджеты акчалары хисабына гамәлгә ашырыла.

10. Әгәр реклама корылмасы муниципаль мөлкәт объектына яки күп фатирлы йорттагы бүлмә хуҗаларының гомуми мөлкәтенә әлеге бүлмә хуҗаларының реклама корылмасын урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә ризалыгыннан башка тоташтырылса, әлеге тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән очракта, аны демонтажлау, саклау яки кирәк очракта юкка чыгару шәһәр бюджеты акчалары хисабына гамәлгә ашырыла.

11. Тышкы мәгълүмат чарасының хуҗасы тарафыннан әлеге тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән срокта АШТ һ ТҮИ күрсәтмәсе үтәлмәгән очракта, тышкы мәгълүмат чарасын демонтажлау җирле бюджет акчалары хисабына гамәлгә ашырыла.

12. Реклама корылмасының, тышкы мәгълүмат чарасының хуҗасы, реклама корылмасы тоташтырылган күчемсез мөлкәт милекчесе яки аның башка законлы хуҗасы билгеле булмаган очракта, АШТ һ ТҮИ реклама корылмасын, тышкы мәгълүмат чарасының фотосурәтен теркәп, демонтажлау турындагы күрсәтмәне «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыра. Бу очракта күрсәтмәне сайтка урнаштырган дата демонтажлау турында күрсәтмә бирү датасы булып тора.

13. Җирле бюджет хисабына демонтажланырга тиеш булган реклама

корылмаларының, тышкы мәгълүмат чараларының исемлеге Башкарма комитет боерыгы белән раслана.

14. Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенә күздә тотылган демонтажлау турында 1 (бер) көн алдан хәбәр ителә.

15. Демонтажлау АШТ һ ТҮИ вәкаләтле вәкиле катнашында «Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ санлы Федераль законда каралган тәртиптә төзелгән килешү нигезендә подрядчы оешма тарафыннан башкарыла.

16. Башкарылган демонтаж турында АШТ һ ТҮИ акт төзи, анда демонтажлау урыны, вакыты күрсәтелә, реклама корылмасының, тышкы мәгълүмат чарасының демонтаж эшләре башланганга кадәрге һәм алар тәмамланганнан соңгы техник торышы тасвирлана, шулай ук демонтажлауны башкаручы оешма хезмәткәрләренең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме күрсәтелә.

17. Демонтажлау гамәлгә ашырылган көннән соң өч эш көненнән соңга калмый, АШТ һ ТҮИ реклама корылмасының, тышкы мәгълүмат чарасының хуҗасына яки демонтажланган реклама корылмасы тоташтырылган күчемсез мөлкәт милекчесенә яки аның башка законлы хуҗасына башкарылган демонтаж турында белдерү кәгазе җибәрелә. Реклама корылмасының, тышкы мәгълүмат чарасының хуҗасы ачыкланмаган, шулай ук реклама корылмасы тоташтырылган күчемсез мөлкәт милекчесе билгеле булмаган очракта, АШТ һ ТҮИ өч эш көне эчендә башкарылган демонтаж турында белдерү бастыра һәм Интернет челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыра.

18. Башкарылган демонтаж турында белдерү язуы алган датадан соң алты ай эчендә демонтажланган реклама корылмасы, тышкы мәгълүмат чарасы хуҗасы тарафыннан сорап алынмаган очракта, реклама корылмасы, тышкы мәгълүмат чарасы суд тәртибендә хуҗасыз дип танылырга тиеш.

19. Реклама корылмасын, тышкы мәгълүмат чарасын мәҗбүри рәвештә демонтажлау гамәлгә ашырылган очракта, реклама корылмасының, тышкы мәгълүмат чарасының хуҗасы яисә реклама корылмасы тоташтырылган күчемсез мөлкәт милекчесе реклама корылмасын, тышкы мәгълүмат чарасын демонтажлау, аны транспортлау һәм саклау белән бәйле рәвештә Башкарма комитет тарафыннан тотылган чыгымнарны түләргә тиеш.

20. Реклама корылмаларын һәм тышкы мәгълүмат чараларын демонтажлау, аларны транспортлау һәм саклау чыгымнарын түләтүне исәпләү реклама корылмаларын һәм тышкы мәгълүмат чараларын демонтажлау, аларны транспортлау һәм саклау эшләре өчен Башкарма комитет тарафыннан подрядчы оешмага түләгәндә фактта тотылган чыгымнар буенча башкарыла.

21. Реклама корылмасын демонтажлау турында күрсәтмә, тышкы мәгълүмат чарасын демонтажлау турында күрсәтмә бирүдән, реклама корылмасын, тышкы мәгълүмат чарасын демонтажлаудан риза булмаган очракта, тиешле күрсәтмәне алган (тиешле күрсәтмә басылып чыккан) көннән соң яки реклама корылмасы, тышкы мәгълүмат чарасы демонтажланган көннән соң өч ай эчендә судка яки арбитраж судка шикаять бирергә мөмкин.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Управление делопроизводством
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе

Г.К. Әхмәтова